КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 11 февраль г.Казань № 113

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге турында» 1997 елның 16 октябрендәге 783 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе турында» 1997 ел, 16 октябрЬ, 783 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2001 ел, 15 октябрь, 758 нче, 2006 ел, 28 декабрь, 651 нче, 2008 ел, 8 май, 296 нчы, 2011 ел, 3 декабрь, 989 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 30 март, 195 нче карары белән җайга салына дип билгеләргә».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин